


Ул ДНР, ЛНР, Запорожье һәм Херсон олкәләренен Россия Федерациясе белән берләшv конөнә туры килә.
Кvргәзмәдә тарихи экскурсия тәкъдим ителде: 1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышы елларында Украина территориясендә немец фашизмына каршы корәш очен бvләк-ләнгән Мордовиялеләрдән алып, бvген махсус хәрби операциядә катнашкан, илебезне, яна Россия тобәкләрендә яшәvче тыныч халыкны яклаучы республикада туганнарга кадәр.

Ләмберә районы Пензяткалылар арасында илебезнен ин зур хөрмәтенә лаек булган Советлар Союзы Герое - Асыйм Айзятулла улы Баляевнын фотосы да шул кvргәзмәдә.
Асыйм Айзятулла улы Баляев (Алексей Андреевич Баляев) 1923 елнын 15 августында Пензятка авылында крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан сон Калинин олкәсендә, «Волгострой» предприятиесендә эшли. 1941 елнын ноябрендә Кызыл армия сафында хезмәт итәргә чакырыла. 1941 елнын декабреннән Боек Ватан сугышы фронтларында. Коньяк-Конбатыш фронтынын 6-нчы армиясе 25-нче гвардия укчылар дивизиясенен 78-нче гвардия укчылар полкында укчы була. Днепр очен сугышта батырлык кvрсәтә. СССР Югары Советы Президиумынын 1944 елнын 19 мартындагы Указы белән кызылармеец Асыйм Айзятулла улы Баляев Советлар Союзы Герое исеменә лаек була, ана Ленин ордены һәм «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.
Асыйм Айзятулла улы 1946 елда демобилизацияләнә һәм Мәскәv олкәсенен Ногинск шәһәрендә яши. 1983 елнын 25 сентябрендә vлә. Батырлыклар кvрсәткән очен берничә медаль белән бvләкләнә.
Туган авылы Пензятка урта мәктәбендә, «Герой партасы» проектында катнашып, Асыйм Айзятулла улы Баляевнын фотосы, кыскача биографиясе, анын турында мәгълvмат язылган парта бар. Шулай ук партада мобиль жайланмалар очен QR-код урнаштырылган, аны сканерлап, укучы герой турында мәгълvмат тәкъдим ителгән рәсми порталга эләгә.